**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**СТАРОКУТУШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

Свежухина, дом 33, с.Старые Кутуши, 423116

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ КОТЫШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Свежухин урамы,33 йорт, Иске Котыш авылы,
423116

Тел(84396)2-72-47 Skut.Cmn2@tatar.ru

№ 63 15.11.2022 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Котыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Җирле салымнар буенча
недоимкалар, бу салымнар буенча
пенялар һәм штрафлар буенча
бурычлар түләтүгә өметсез дип
тануның өстәмә нигезләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 – ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Төбәк салымнары буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2017 елның 19 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Җирле салымнар буенча недоимкалар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычлар түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә (алга таба – бурыч):

1) мирас ачылган көннән бер ел эчендә варислар баш тартканда яки булмаганда үлгән яки үле дип игълан ителгән (яисә өч елдан артык бурыч барлыкка килгән көн белән);

2) бетерелгән җирле салымнар (реструктуризация режимында һәм банкротлык процедураларында булган салым түләүчеләрнең бурычларыннан тыш);

3) суд приставлары тарафыннан «Башкарма производство турында» 02.10.2007, №229-ФЗ Федераль законның 46 һәм 47 статьяларының 1 өлешенең 3,4 пунктына ярашлы рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында карар чыгару;

4) недоимкага исәпләнгән юридик затларның пенялар буенча бурычы булу, аны түләтү срогы тәмамланганнан соң, алар исәпләгән недоимка булмаганда.

5) бурычның барлыкка килү датасы белән 3 елдан артык түләтеп булмый дигән акт булу

6) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр недоимка яки бурычның булуы;

7) суд карары белән хокукый сәләтсез дип танылган психик тайпылышлар булган затлар;

8) картлар йортларында яшәүче затлар;

9) иректән мәхрүм итү урыннарында булган затлар, иректән мәхрүм итү урыннарында булган чорда;

10) җирле үзидарә органнарының раслаучы документлары булганда аз керемле физик затлар;

11) ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән ата-аналарның балалар йортларында һәм приютларда тәрбияләнүче балигъ булмаганнар балалары;

12) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында мәгълүматлары булмаган юридик затлар.

2. Салым түләүченең бурычын гамәлдән чыгару салым органы тарафыннан әлеге карар, салым түләүченең бурычы турында белешмә, тапшырылган документлар нигезендә башкарыла.

3. Алар нигезендә гамәлдән чыгару ясалырга тиешле документлар юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр, физик затлар тарафыннан салым органына тапшырыла.

4. Әлеге карар үзенең гамәлен бурыч барлыкка килгәннән бирле барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә тарата.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль
районы Иске Котыш
авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе А.К.Митякин